МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА им. Г. ИБРАГИМОВА

# НАСЛЕДИЕ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ В КОНТЕКСТЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР

МАТЕРИАЛЫ
МЕЖДУНАРОДНОЙ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОЙ КОНФЕРЕНЦИИ,
ПОСВЯЩЕННОЙ 125-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

(25 апреля 2011 г.)

КАЗАНЬ
2011

**УДК 80(=512.145)+7(=512.145)+008**
**ББК 80(2Тат)+85(2Тат)+70ж**
**Г12**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла

**Редколлегия:**
***К. М. Миңнуллин** (рәис), **М.Х. Вәлиев, Д. Ф. Заһидуллина,***
***И. М. Ибраһимов, Х. Ш. Мәхмутов, З. З. Рәмиев, Н. Ш. Хисамов***

**Төзүчеләр:**
***Э. М. Галимҗанова, Г. А. Хөснетдинова***

**Фәнни редактор**
***Р. М. Кадыйров***

**Г12 Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнешләр:** Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). – Казан, 2011. – 315 б.
ISBN 978-5-93091-133-6

Җыентыкка татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары тупланды. Аларда шагыйрьнең тормыш юлы, иҗат мирасы, башка әдәбиятлар белән бәйләнеше мәсьәләләре, сәнгатьтә (музыкада, театрда, рәсем сәнгатендә һ. б.) чагылышы, башка телләргә тәрҗемәләре турында сүз бара.

**ISBN 978-5-93091-133-6**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2011

**Г. М. Хасанова** *(Казань).* Жизнь и творчество Тукая в трудах Мухаммета Магдеева (на материалах личного архива ученого и писателя) . . . 139

**Р. Ф. Харрасова** *(Казан).* Тукай, Иванов-Классик һәм Никитин . . . 142

**М. И. Ибрагимов** *(Казань).* Г. Тукай и А. Блок: к проблеме сопоставительного изучения поэтики татарской и русской литератур начала XX века . . . 144

**Э. М. Ханова** *(Казан).* Г. Тукай һәм Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында күтәрелгән милли мәсьәләләр . 146

**Г. Р. Гайфиева** *(Казан).* М. Хуҗин хикәяләрендә Тукай образы сурәтләнеше . . . 148

**М. С. Арсланова** *(Стерлитамак).* Воспитательная роль произведений Габдуллы Тукая (на примере «Су анасы» и «Шурале») . . . 149

**А. И. Конова, Н. Г. Гараева** *(Казань).* Новый арабский перевод «Шурале» Г. Тукая . . . 150

**М. Х. Вәлиев** *(Казан).* Тукай һәм «Мәгариф» нәшрияты . . . 153

**Л. И. Минһаҗева** *(Казан).* XX гасыр башы балалар әдәбиятын үстерү юнәлешендә Г. Тукай эшчәнлеге . . . 154

**Ф. М. Сабирова** *(Алабуга).* Габдулла Тукайның балалар поэзиясендә табигать белеме . . . 156

**Н. Ш. Насибуллина** *(Казань).* Традиции Тукая в поэзии Р. Миннуллина . . . 159

**И. Р. Низамова** *(Казан).* Г. Исхакый һәм Г. Тукай әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемасы . . . 161

**Р. И. Сәйфуллина** *(Казан).* Шекспир һәм Тукай . . . 165

**Д. Р. Агзамова** *(Казань).* Фантастическое в «Вечерах на хуторе близ Диканьки» Н. В. Гоголя и в поэмах Г. Тукая «Су анасы», «Шурале» . . . 167

**С. Ф. Галимов** *(Казан).* Г. Тукай һәм З. Бәшири . . . 170

**А. Я. Янмурзина** *(Казан).* Г. Тукай һәм М. Җәлил иҗатларында шагыйрь образы идеалы . . . 172

**Н. Н. Сабирҗанов, Г. Ф. Мамина** *(Казан).* XX йөз башы төрки әдәбиятлары мохитендә Г. Тукай иҗаты . . . 174

**Г. Ф. Сибгатова** *(Казан).* Татар милләтенең рухи яңарышында Габдулла Тукайның урыны . . . 177

**Ф. К. Дәминова** *(Казан).* Тукай варислары . . . 179

**Л. И. Гобәйдуллин** *(Казан).* Габдулла Тукай мирасы (шагыйрьнең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган сирәк басмалары турында) . . . 181

**Н. Ә. Сафина** *(Казан).* Д. Гобәйди иҗатында Г. Тукай традицияләре һәм параллелизмнар . . . 183

**Л. М. Шәехов** *(Казан).* Татар шигъри трагедияләрендә Тукай образы . . . 186

**А. Р. Хафизова** *(Нефтекамск).* Г. Тукай һәм Р. Миңнуллинның гражданлык лирикасында уртак мотивлар . . . 189

**З. И. Сафина** *(Уфа).* Габдулла Тукай һәм Әхсән Баян шигърияте . . . 191

**А. А. Хәйруллина** *(Казан).* Габдулла Тукай һәм Мәхмүт Хәсәнов иҗатларында табигать образы . 193

**Ф. Н. Шәрипова** *(Яр Чаллы).* Габдулла Тукай — безнең тормышта . . . 195

**З. Н. Исламова** *(Әлмәт).* Тукай мирасын математик лицей шартларында куллану тәҗрибәсе . . . 197

## «И туган тел, и матур тел...»

**М. З. Закиев** *(Казань).* Тукай и этнические корни татарского народа . . . 199

**Г. И. Кульдеева** *(Астана).* Национальный язык в контексте теории этногенеза Л. Н. Гумилева . . 201

**Д. Б. Рамазанова** *(Казан).* Г. Тукай һәм XX гасыр башы татар әдәби теле . . . 204

**И. Б. Бәширова** *(Казан).* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле һәм Габдулла Тукайныңбашлангыч чор иҗаты . . . 207

[illegible] вә госманлы әдәбиятыннан әхез иделмеш кыска-кыска гыйбрәтле хикәяләрдер. Мөмкин кадәр татар мәгыйшәтенә борыбрак язылмыштыр. Әсәре Габдулла Тукаев»,— дип куелган (2, 122).

Соңыннан Г. Тукай «Мәҗмугаи мөфидә»дә басылган 66 мәсәлнең 59 исемдәгесен, беркадәр редакцияләп, телен-стилен җиңеләйтеп, яңадан мәсәлләр өстәп, барлыгы 77 мәсәлне эченә алган «Энже бөртекләре» (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы, 1909) исемле җыентык чыгара.

Г. Тукайның прозасы кыска күләмле, фикергә бай һәм үтемле булуы белән игътибарны җәлеп итә, аның чәчмә әсәрләренә халык мәкальләрендәгечә тирән акыл, тапкырлык хас. Атап әйткәндә. «Аю мәҗлесе», «Мактанчык куян», «Чүлмәк илә Казан», «Чабак», «Ташбака илә Куян», «Ике күгәрчен» һ. б. мәсәлләрен укып, балалар күпьяклы тәрбия һәм тәҗрибә алалар. Мәсәлән, «Әтәч илә Энже бөртеге» хикәясеннән чыгарылган нәтиҗә бик мәгънәле. Энже бөртегенең бәһасен аңламаган әтәч, аны тары бөртегеннән дә түбән куя. Әлбәттә, бу — образлы сурәт, түбән, тар фикерле кешеләрнең аерым кыйммәтләрне аңламавына матур мисал. Яки «Чүлмәк илә Казан» хикәяте. Чуеннан эшләнгән Казанга дус булырга теләп, аңа ияреп сәфәр чыккан балчык Чүлмәкнең «теткәләнеп беткән кисәкләре» генә кабат әйләнеп кайта. Биредә дә фикер ачык — дуслар бер-берсенә тиң булырга тиеш. Яки, «Мөһәндис» — беркадәр табышмак уенын хәтерләткән мәсәл. Чөнки укучы, баштан ук, эш нәрсә белән төгәлләнер икән, дип фараз кылырга мәҗбүр. Бу урында Г. Тукайның балалар психологиясен тирән төшенүен ассызыклау урынлы булыр. Мәсәлдә сүз «падишаһлар сарае кебек зур» өен су янына күчерергә теләгән Җегет турында бара. Әмма, ахыр чиктә өй ишелә, күп кешеләр аста калып вафат була. Г. Тукай тормыш тәҗрибәсе аша, үзе үк ахырдан нәтиҗә чыгара: *«Дөньяда бәгъзе кешеләр бар: аларның уе бу мөһәндис фикереннән дә куркынычлырак».*

Г. Тукайның балалар өчен язылган хикәяләре дә кызыклы. К. Насыйриның «Буш вакыт»ын хәтерләткән аерым хикәяләрдә, мәсәлән, табигать турында мәгълүматлар бирелә. Аның иҗатында, шулай ук, тормыш-көнкүреш мәсьәләләренең бала рухына туры китерелеп яктыртылганнарын да очратырга мөмкин. Аерым алганда, «Кояш», «Һава», «Су», «Елның дүрт фасылы», «Һәрнәрсәнең үз урыны бар», «Әлифба», «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару» һ. б. — шундыйлардан.

Г. Тукай — мәктәпләр өчен дәреслек-хрестоматияләр авторы да. Аның «Яңа кыйраәт» («Яңа уку китабы»), «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хезмәтләре озак вакытлар кулланышта булып, үрнәк ролен үтәделәр.

Шулай итеп, узган XX гасыр башында балалар әдәбиятының ныклап үсеш ала башлавы турыдан-туры Г. Тукай исеме белән бәйләнә. Алга таба, Г. Тукай традицияләрен дәвам итүчеләр тырышлыгы белән әлеге өлкә һәртөрле жанрларда һәм төрләрдә үсешкә ирешкән эстетик системага әверелә.

ӘДӘБИЯТ


1. Кукушкин Р. Шигъри бишек / Р. Кукушкин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.
2. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. III т. Мәкаләләр, хикәяләр, мәсәлләр / Төз. Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 448 б.
3. Тукаев Г. Мөкаддимә // Тукаев Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.
4. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
5. Тукай Г. Кызыклы шәкерт / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.


# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ БАЛАЛАР ПОЭЗИЯСЕНДӘ ТАБИГАТЬ БЕЛЕМЕ


***Ф. М. Сабирова (Алабуга)***



В статье рассмотрены стихотворения поэта, в которых просто и в то же время в ярких эмоциональных образах воссозданы те или иные явления природы. Дети не должны ограничиваться восприятием лишь внешних, видимых признаков явлений природы. Важно, чтобы они прочувствовали и то, что хочет сказать детям поэт, что его волнует, беспокоит и как, какими художественными средствами выражает он свои переживания. В связи со сложностью решения такой задачи в статье разработаны рекомендации, которыми могли бы воспользоваться как родители, так и воспитатели и учителя при изучении или просто чтении произведений Габдуллы Тукая.


«Балалар — тормыш чәчәкләре», «балалар — безнең киләчәгебез» кебек, көн дә диярлек, күтәренке, пафос белән әйтелә торган гыйбарәләрнең чын мәгънәсен Габдулла Тукай моннан 104 ел элек үк (1907 елның маенда) саллырак һәм үтемлерәк итеп әйткән: *«— Балалар — безнең шатлыкымыз... Балалар — безнең бәхетемез вә сәгадәтемез.. Балалар безнең гомер нигеземезне тазарталар, балалар хезмәт өчен безнең көчемезне арттыралар»,* — дигән ул үзенең «Ана мәктүбләре» дигән хезмәтендә (3, 115). Бу сүзләрнең ата-ана йөрәгеннән киселеп чыкканлыгын кисәтә шагыйрь, начар яки яхшы тәрбиянең нәтиҗәләренә ачыклык кертә. Шунысы да мөһим: гаять күп санлы шигырьләре белән Тукай ата-аналарга гына түгел, тәрбияче һәм укытучыларга да яшь буынга әхлак, хезмәт, физик һәм башка юнәлешләрдә тәрбия бирү бурычларын гамәлгә ашырырга ярдәм итә. Бу мәкаләдә балаларны бары тик табигать белеменнән мәгълүматлы иткән шигырьләренә генә күзәтү үткәрелә.

Бәхеткә, балалар бакчасы һәм башлангыч сыйныфлар өчен төзелгән программаларга Габдулла Тукайның күп кенә шигырьләре кертелгән. Аларны

дәрестән тыш вакытта да укырга-өйрәнергә була. Мәсәлән, балалар бакчасында елның һәр вакыты Г. Тукайның «Елның дүрт фасылы» әсәреннән өзек уку белән каршы алына. Менә урамга яки кырга (һичьюгы ишек алдына) бергәләп чыккан нәниләргә тәрбияче әлеге әсәрдән бер строфаны укый:

*Кырлар буш кала,*
*Яңгырлар ява;*
*Җирләр дымлана, —*
*Бу кайчак була?* (2, 147).

Җавапны балалар әйтә. Кызыклы гына башланган табышмак әйтеш дәвам итә: җир ни өчен дымлана? Юешләнү нәрсә дә, дымлану нәрсә? Көз көнендә тагын нинди үзгәрешләр күзәткәнегез бар? Яңгырлар җәй көне дә ява, һәм җир дымлана... Аерма нәрсәдә? «Кырлар буш кала» дигәнне сез ничек аңлыйсыз? Әйе, бу арыш кырлары, бодай басулары, бәрәңге-яшелчә бакчалары гына түгел, ә бәлки иксез-чиксез дигәнне дә аңлата. Киң болыннарны, яр буйларын, печәнлекләрне күз алдына китереп, колачлап алырга тырышыйк әле... Ахырдан гади генә ике нәтиҗә ясап куела: шагыйрь көзнең барлык билгеләрен дә әйтеп бетерми, андый эшне ул укучыга калдыра («читатель» мәгънәсендә), шигырьдәге сүзләрне дә киң, тирән мәгънәдә аңлавына өмет итә; дөнья — очсыз-кырыйсыз киңлек ул, үсә-үсә андагы төрле серләрне, билгеләрне ачарга туры килер әле... Күрәбез, методик табышларны Тукай, әсәренең эчтәлеге һәм поэтикасы аша, үзе үк әйтеп тора.

Кышны каршыларга да балалар янына Тукай килә:

*Һәр җир карланган,*
*Сулар бозланган;*
*Уйный җил, буран, —*
*Бу кайчак, туган?* (2, 147).

Кышкы табигатьтәге үзгәрешләргә игътибар юнәлтү белән бергә, шагыйрьнең якын итеп үзе белән уенда катнашучыга «туган» дип дәшүе — мөһим деталь. Бергә-бергә уйнаганда, эшләгәндә, укыганда үзара дус, туганнарча тату булырга сабак булып аңлашыла бу, бала-чага аңларлык әхлакый кагыйдә. Шигърият акыл сату, вәгазь сөйләүне яратмый, ә нинди дер бер сүз, деталь белән тирән мәгънәле мәгълүмат бирә. Турыдан-туры фәнгә кагылышлы деталь дә бар: сулар бозлана... Билгеле бер шартларда, ниндидер тәэсирләр йогынтысында табигать дөньясында бер күренеш икенче күренешкә, бер әйбер бөтенләй икенче сыйфаттагы әйбергә әверелә.

Язны житкерик:

*Боз һәм кар эреде,*
*Сулар йөгерде;*
*Егълап елгалар,*
*Яшьләр түгелде.*

*Көннәр озая,*
*Төннәр кыскара,*
*Бу кайсы вакыт? —*
*Йә, әйтеп кара* (2, 147).

Бер-бер артлы рифмик яктан нык берегеп килгән гади җыйнак җөмләләргә һәм образлы сүзләргә (сулар йөгерә, елгалар җылыйлар) табигать белеменең ике бүлеге урнаштырылган. Бердән, җир йөзендәге яз көннәрендә күләмнәре бермә-бер артып киткән елгалар, күлләр, диңгезләр һ. б. ларның сулары яз җылылыгында парга әйләнәләр һәм югары күтәреләләр, аннары, анда үзара кушылу сәбәпле, парлар авыраялар һәм җиргә яңгыр булып явалар. Икенче мәгълүмат Җирнен үз һәм Кояш тирәсендә әйләнүенә кагыла. Әсәрдәге фигыльләрнең үткән заманда икәнлегенә игътибар иткәндә, шагыйрьнең Җирнең Кояшка шактый якынайган вакытын, озакламый җәй житәчәк чорны тасвирлаганы аңлашыла.

**«Җәй»** шигыре тиз-тиз үзгәрүләр, тыгыз хәрәкәтләр белән тулы: ашлыклар үсеп, «пешеп» тә өлгерә, коелгалаганчы, урырга кирәк. Халыкның, шулай булгач, ашыгуы табигый. «Җәйге бер көн ел туйдыра» дигән халык мәкале искә төшә.

Ел фасылларын Тукай кайта-кайта, янадан-яңа үзенчәлекләрен ача-ача тасвирлый. Лирик герой хисләренең чагылышы аша язгы табигатькә шагыйрьнең уңай мөнәсәбәтен, андагы үзгәрешләргә сизгерлеген, уңай бәясен төсмерлисең.

**«Кышка бер сүз»**дә бертөрле күңел күтәренкелеге белән кыш-яз тартышы җанландырыла, табигатьтә һәрнәрсәнең үз катгый тәртибе булу сәбәпле, гөлләр патшасы язның аллы-гөлле күбәләкләр гаскәре белән алтын фаэтонында барыбер киләчәгенә куану, хуплау белдерелә.

**«Яз галәмәтләре»** язга һәркемнең (яше, карты) шатлануын хәбәр итә.

**«Яз хәбәре»**ндә табигатьтәге яңарышларга үз мөнәсәбәтен Тукай укучысына карлыгач сайравы аша житкерә:

*«Купме, февраль, каш җыерсаң һәм ачулансаң да син,*
*Барыбер, ди, җитте яз һәм рухына кышның ясин»* (2, 123).

**«Яз»** шигыре моңа кадәр телгә алынган әсәрләрдән үзенең фәлсәфи юнәлеше белән аерылып тора: лирик герой каләмен язарга, иҗат итәргә өнди: нурлы, якты яз килгән бит. Шул ук вакытта каләм туктап калган, герой нәрсәнедер аңлап бетерми кебек. Әйе, тормышка нур иңә, яз килә, әмма анда мәхшәр: бозлар, ахыр заман җиткән кебек, бер-берсен кага-кага агалар, чабалар, үлекләр гаскәре кебек, бетүгә баралар. Кайсының җәннәткә, ә кайсының утка барганлыгын белеп да булмый. Җирдән чыккан парлар һәм томаннар да ахыр заманны искә төшереп тора:

*Бу галәмне тота бертөрле каушау,*
*Бөтенләй болганадыр, килә шау-шау* (1, 153).

Әнә шулай шагыйрь яңалыкның искелек белән тартыша-тартыша хакимлеккә ирешүенә (каршылыклар тартышы), җиңүенә табигать дөньясындагы үзгәреш-хәрәкәтләрне сәнгатьле сүз белән җанландырып инандыра.

**«Яз галәмәтләре»** дип исемләнгән икенче бер шигырендә «яз һәм кеше», «табигать һәм иҗтимагый тормыш» параллельләре күзәтелә.

Көз — Тукайда каршылыклы хис-кичерешләр уята торган вакыт. Бер карасаң, көзнең дә күңеленә хуш килә торган яклары юк түгел икән: *«...уҗым/ Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем»* (**«Көз»**); *«...Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар»* (**«Чыршы»**). Шулай да тискәре тәэссоратлар күчлерәк:

[illegible] *тиеле, арта сары төс...»* (**«Чыршы»**); *[illegible] зәгъфыран саргайды урман», «Тәэссеф! [illegible] золмәт, китте якты».*

*Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;*
*Чәчәксез көз, уләнсез һәм дә гөлсез* (1, 110).

Көзгә карата мондый тискәре мөнәсәбәтнең сәбәпләре Тукай биографиясен белгән кешеләргә ачык: көзләрен шагыйрьнең авыруы аерата кискенләшә, кием-салымның һәм яшәү-тору урынының җылылыгы мактанырлык түгел. Шуна күрә дә «Көз» шигырендәге түбәндәге юллар гаҗәп тоелмый:

*Үлеп торсам иде мин алты айдай,*
*Эреп бер йокласам мин сары майдай.*
*Шулай йоклап, бәһар җиткәндә торсам,*
*Торып тагы яшел җирдә утырсам,* — (1, 111)

Нинди генә күңелсез хисләргә чорналмасын, көзге табигатьтәге чак сизерлек дәвамлы үзгәрешләрне, Габдулла Тукай нечкәләп-нәфисләп тасвирлап бирмәсә, бала-чагаларыбыз белән бергә, белми-күрми (гади күз бит) гомер кичергән һәм, эстетик яктан булсын, аң-белем җәһәтеннән булсын, күп нәрсәләрне югалткан булыр идек. Шагыйрьнең табигать дөньясын оптимистик рухта, олуг бер мәхәббәт белән җанландырган әсәрләре дә иксез-чиксез.

Турыдан-туры «Җәй» дип исемләнгән әсәрләр Тукайда күп түгел. Мисалга «Җәй көнендә» шигырен (һавадагы эсселек, бөркүлек, корылык һәм... балаларның иртәдән кичкә кадәр ак балыклар кебек йөзүләре), «Яңа кыйраәт» хрестоматиясеннән томлыкларга кертелгән «Җәй» мәкаләсен (җәйге табигатьнең төп билгеләре, авыл һәм шәһәр халкының җәйге мәшәкатьләре) алырга мөмкин. Аның каравы җәйге табигать хозурлыгын Тукай күп юнәлешләрдә бирүгә ирешә:

***туган җир табигатенең*** гүзәллеге, изгелеге: «Җәйге таң хәтирәсе», «Шүрәле», «Туган авыл», «Туган жиремә»;

***балалар һәм табигать***: «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Су анасы», «Бала белән Күбәләк», «Бичара Куян», «Кызыклы шәкерт», «Кошчык»;

***кош-корт, хайваннар дөньясы***: «Кошларга», «Карлыгач», «Һәркемнең ашыйсы килә», «Ялкау маэмай», «Сөткә төшкән тычкан»;

***күк җисемнәре, ел, тәүлек әйләнәсе***: «Ай һәм Кояш», «Яңгыр илә Кояш», «Арба, Чана, Ат» һ. б., һ. б.

Әлбәттә, үзенең тәрбияви эчтәлеге, гади һәм образлы теле белән иҗат ителгән шигърияте аша шагыйрь балаларның аң-белемен үстерүгә үзе дә ирешә. Ә инде тәрбияче яки укытучы да, шагыйрь белән бергәләп иҗат итешкәндәй, шигырьнең төпкә яшеренгән серләрен дә ачарга ярдәм итсә, нур өстенә нур инде ул. Мәсәлән «Җил» шигырен укыгач, җилнең ниләр кылганлыгын санап китү, аның кочена соклану аз. Җил һәм аның хәрәкәтләренә салынган эчке мәгънә — ирекка сусау, ирекле булырга омтылыш икәнлеген төшенү дә кирәк. Киеренке эчке рухи халәт белән бәйле шигырьләргә аерата игътибарлы булу мөһим. Мисалга «Яратырга ярый» шигырен китерик. Әсәр эчтәлегенә килгәндә, елның һәр фасылы яратуга лаек, һәрберсе матур, димәк, дөнья матур: *«...матур кырлар, матур таулар»...* Әнә шул матурлык фонына шагыйрь контраст итеп тормыштагы үзәген өзгән ямьсезлекләрне куя: фәкыйрьлек, ярлыларның газаплы тормышы, кеше дип әйтергә тел бармаган адәм актыклары... Җирдә, табигать кочагында тормыш, төрле кешеләр бар, дигән сүз бу. «Шатлык вә хәсрәт» шигыренә дә тирән мәгънә салынган. Әле генә дөньяны болыт каплаган, яшен яшьнәп, яңгыр яуган, ялтырап кояш чыккан иде. Ләкин күп тә үтми, диңгез өстендә куе, кара, ямьсез болытлар пәйда була. Нишләмәк кирәк, тормыш та, кеше күңеле дә бер генә халәттә тормый, дөньяда статик, катып калган күренешләр юк бит ул.

*Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә кояш бергә;*
*Шулай бергә бугай: шатлык та хәсрәт, канлы яшь берлә*
(1, 254).

Бик тә үзенчәлекле төзелгән «Шигърият һәм нәсер» әсәре турында берничә сүз әйтми булмый. Әсәрнең буеннан-буена һәр строфаның беренче ике юлында тәүлекнең һәр мизгеле: ямьле кич, айлы төн, ак йолдызлар, кош тавышлары, якты таң, кояш калку һ. б. — барысы да гаҗәеп матур төсләр, авазлар үзенә хас табигый хәрәкәтләр белән җанландырыла. Шул уңай белән һәр строфаның өченче-дүртенче юллары үз тәртибендә төрле катлам кешеләренең үзара һәм байлыкка, акчага, өстенә салынган йөкләмәгә мөнәсәбәтен әле юмор, әле бер ачыну хисләре белән ача бара. Шигърият шундый серле, гаҗәеп нәрсә инде ул: табигать гүзәллеген тормыш-яшәеш хәл-әхвалләрен дә бергә колачлап, һәркем аңларлык итеп төшендерү куәтенә ия.

Инде нииндидер өстәмә аңлатуларга мохтаҗлык һич юк кебек тоелган «Шүрәле» әсәренә карата берничә сүз. Монда Тукайның гүзәл табигать күренешләрен табигатьнең үзеннән дә гүзәлрәк итеп тасвирлавына инану гына аз. Әсәрдәге күренешләрне, предметларны, төс-ис, аваз, хәрәкәтләрне таный белеп, ачыклап-аңлатып күрсәтә алу да житенкерәми. Әсәрнең буеннан-буена үтәләп барганы — туган ягына гашыйк, тугрылыклы, игелекле кеше хисләре, ничәмә-ничә төсмерле хисләр гармониясе: искә төшереп әсәрләнү, сагыну, ярату, горурлану, хозурлану, соклану, хәтта мактану. (*«Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;/ Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк»*). Әсәрдә ачык, җанлы, төгәл, куе төсләр белән бирелгән табигать күренешләре — шагыйрьнең табигать улы, туган җиренең игелекле улы булуына олуг бер дәлил ул.

Беренче карашка бик тә гади, көлкеле тоелган «Сөткә төшкән тычкан» әсәрен алыйк. Балалар белән бергәләп, күңелдән генә сөт чүлмәгенә кереп, чыга алмый тыпырчынып яткан тычканны «күзәтүе» кызык инде. Ләкин тычкан аптырап калмый, болгатудан барлыкка килгән май өстенә басып чыгып, бәладән котыла. Гадәттә бу шигырьне укыгач, шул аңлашыла: югалып калмаска, хәрәкәттә булырга кирәк. Әлбәттә шулай. Тик балага сорау биреп куясы иде: ничек алай майга басып котылырга мөмкин булган? Дөрес, май каты булганга. Ә ничек май төпкә батмаган? Өстә йөзеп йөрмичә, төпкә баткан булса, тычкан чыга алмаган

булыр иде бит... Мондый характердагы аңлашулар (Ник? Нигә? Ничек анларга? Ни өчен?) әледән-әле булып торса, балаларга киләчәктә фән нигезләрен үзләштерүне (бу очракта, әйтик, «сыеклык», «каты җисем» төшенчәләрен, Архимед законы белән аңлатылган күренешләрне һ.б.ны) күпкә җиңеләйтер иде.

Йомгак ясап, шуны гына ассызыклап куярга кирәк: Габдулла Тукай шигырьләрендә һәм аң-белем, һәм тәрбия бирү мөмкинлекләре иксез-чиксез. Аларны укыту-тәрбия эшендә файдалана белергә генә кирәк.

### ӘДӘБИЯТ


1. Тукай Габдулла. Әсәрләр: 5 томда / тоз. Р. Гайнанов; кереш сүз авт. Г. Халит. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985–1986. – I т.: шигырьләр, поэмалар (1901–1908) – 408 б.

2. Тукай Габдулла. Әсәрләр: 5 томда. – II т.: шигырьләр, поэмалар (1909–1913) – 400 б.


# ТРАДИЦИИ ТУКАЯ В ПОЭЗИИ Р. МИННУЛЛИНА


***Н. Ш. Насибуллина (Казань)***


Творческое наследие Тукая составляет гордость татарского народа, его имя навеки связано с прошлым, настоящим и будущим национальной культуры. Он сыграл поистине выдающуюся роль в развитии культуры и литературы всех тюркоязычных народов на-

Здесь родились мы, здесь росли, вот здесь мы встретим смертный час,
Вот с этой русскою землей сама судьба связала нас.
Прочь, твари низкие, не вам, не вам смутить мечты святые: